**Дания НИГЪМӘТЖАНОВА,**
Чаллы дәүләт педагогия институты
доценты, филология фәннәре кандидаты

# ҖЫРЛЫ ИҖАТ

Әнвәр Шәрипов - филология фәннәре докторы, профессор, әдәбият тарихын тирәнтен өйрәнүче күренекле галим, шигърияттә үз урынын тапкан шәхес. Ул «Кем идең син? », «Зонтиклы кыз» исемле шигырь җыентыклары белән әдәбият яратучыларны үзенә җәлеп итте.

Әнвәр Мәгъдәнур улының җыр жанры өлкәсендә дә шактый гына уңышлары бар. Ул сәнгать әһелләре белән тыгыз элемтәдә яши. Иҗади дуслык нәтиҗәсендә 24 җыры дөнья күрде. Аларның күбесе халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессиональ җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган җырларына әйләнде.

Җыр язу өчен аерым талант, үзенчәлекле образлы фикерләү сәләте, халыкчанлык, гадилек, тумыштан күңелгә салынган музыкальлек кирәктер, мөгаен. Һәрбер шигырьне җыр итеп тә булмый. Моның өчен ритм һәм рифма гармониясе дә, тартык сузык авазларның яисә аерым иҗекләренең ритм хасил итеп кабатланып килүләре дә һәм иң мөһиме, эзлекле, логикалы фикер, идея, хис һәм мәгънә берлек булу да шарт.

Әнвәр Шәриповның җырлары туган җиргә, туган авылга, мәхәббәт һәм гаиләгә, әнкәйләргә багышланган. Әлбәттә күрсәтелгән темалар бер-берсе белән үрелеп баралар. Аның композитор Илгиз Закиров белән иҗат иткән «Ага сулар» җырын яратып башкарам. Җырның эчтәлегендә тәүге мәхәббәт, мәңге онытылмый торган сөйгән яр сурәтләнә:

Ага сулар, ага сулар,
Сулар салкынмыни ул?
Иң беренче сөюләрем
Сунмәс ялкынмыни ул?
*Кушымта:*
Аккан суда күрәм төсле
Гомерем агышларын
Айлар буе. еллар буе
Басылмый сагышларым.

Әсәрнеи тукымасына күңелнең иң тирән төпкелендәге саф һәм нәфис тойгылар сеңдерелгән. Тәүге мәхәббәткә багышланган бу җырның лирик герое үзенең кайнар хисләрен бик тыйнак, әмма ихластан, хәтта сорау формасында белдерә. Ләкин бу риторик сорау, ул җырга күтәренке пафос бирә, сорау куюдан бигрәк, раслау булып та яңгырый.

Ага сулар, ага сулар
Сулар салкын икән шул.
Әҗәлләрем җиткәндә дә
Сунмәс ялкын икән шул.
*Кушымта:*
Агымсулар, бер юл алгач,
Ага да, ага икән.
Сөю уты, бер кабынгач,
Яна да, яна икән.

Бу җыр озын гомерле булды. Мин аны ике дистәгә якын еллар башкарам һәм шул җыр исеме белән аудио кассета чыгардым. Ә. Шәриповнын, мәхәббәт темасына язылган җырлары байтак. «Төшләремдә яшисең», «Соңлап килгән мәхәббәт» (Р. Зарипов көе), «Әгәр аңласаң» (Ш. Нигъмәтуллин көе) һ.6. Бу җырларда гашыйк булу, өзелеп ярату, сагыну, юксыну мотивлары киң урын алган.

Төшләремдә яшисең син.
Төшләремдә юатам.
Төшләремдә очратам да
Төшләремдә югалтам.

(«Төшләремдә яшисең»)

Шунысын әйтергә кирәк: беренче мәхәббәтне юксыну, ул әле лирик геройның гаилә тормышы бәхетсез икән дип уйларга бирми. Бу мотив безнең җыр шигъриятендә шактый еш яңгырый: «Беренче мәхәббәт» (Ә. Рәшитов шигыре. С. Садыйкова көе), «Тәүге сөю» (А. Игебаев шигыре. З. Исмәгыйлев көе), «Яшь наратлар» (И. Юзеев шигыре, Ж. Фәйзи көе), «Яшь гомер» (Г. Зәйнашева шигыре, З. Гыйбадуллин көе). «Мин сине ничек яраттым» (Р. Фәйзуллин шигыре, С. Садыйкова көе) һ.б.

«Мәхәббәт ул һәркемнең йөрәгендә туа, һәм аны һәркем үзенчә кичерә, әмма мәхәббәт газаплары бар кеше өчен дә бертөслерәк», – дип язды, җырчы шагыйрә Гөлшат апа Зәйнашева.

Әнвәр Шәриповның туган ягына, туган авылына багышлап язган җырлары да бик үзенчәлекле һәм патриотик рухта язылган.

«Туган җирне олылау – татар поэзиясенең йөрәк түрендә туган олы хис. Үзләренә җан, илһам биргән, шатлыкта да, кайгыда да, таяныч, өмет йолдызына – туып үскән төбәккә Тукай, Такташ, Туфан, С. Хәкимнәр иң гүзәл шигырьләрен юллыйлар», – дип яза шигъриятебезнең абруйлы белгече Тәлгать Галиуллин. Бу күркәм традицияне Ә. Шәрипов та дәвам итә. Авыл һәм табигать! Табигать һәм туган як. Болар аерылгысыз төшенчәләр. Берсеннән башка икенчесе яши алмый. Аның иҗатында да туган авыл, туган як төп темаларның берсе булып яңгырый. Иң беренче чиратта ул табигатькә мөрәҗәгать итә. Чөнки табигать бетмәс-текәнмәс илһам чыганагы.

Җил җиләкләре кызара
Июль башлары белән
Чиләгемне тутырып кайтам
Җир җиләкләре белән.
*Кушымта:*
Җир җиләге тәмнәре
Тәмләндерә чәйләрне
Шуңа күрә бик яратам
Җир җиләкле җәйләрне.
(«Җир җиләге тәмнәре» Р. Зарипов көе)

Шагыйрь хуш исле, тәмле җир җиләген яратып һәм сокланып кына калмый, «Саклыйк без җиләклекне» дип табигатьне сакларга өнди:

Без табигать баласы бит.
Аңлыйбыз кирәклекне
Киләчәк буыннарга да
Саклыйк без җиләклекне.

Ә. Шәрипов туган җирнең чын патриоты. Автор ихластан үзе туып үскән якларга мәдхия җырлый, аның белән горурлана.

Очар канат бирдең, Кәрәкәшлем.
Күңелем еракларга омтыла.
Тауларыңа менеп бер җырласам.
Бөтен кайгыларым онытыла.
Кушымта:
Сандугачлар сайрый талларында.
Күләгәсе уйный елгада.
Синең кебек матур, синдәй ямьле
Башка җир юк бөтен дөньяда.

Туган авылы – Кәрәкәшле аның теленә, җыр-моңнарына олы мәхәббәт кабызган. Авылының таулары, таллары, җидегән чишмәләре аның җырларының бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы.

Җиде кызын җәйге иртәләрдә
Җидегән чишмәләрдән су ала.
Кызлар йөргән чишмә буйларында
Сулар белән түгелеп моң кала.

Ә.Шәриповның җыр шигъриятендә милләт темасы – халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары һәм бәйрәмнәре үзенчәлекле төсмер алган. Күренекле композитор М. Имашев белән «Сабантуйлы Татарстаным» дигән җыр иҗат иткәннәр алар.

Сөлгеләрне сөлгеләргә ялгап
Их, урарга иде җир шарын
Күрсен иде дөнья Сабантуйлы
Татарстан дигән ил барын.

Шагыйрь бары тик Татарстанда гына утә торган Сабантуй бәйрәме белән ихлас желдән горурлана. Җырның эчтәлегенә тирән мәгънә салынган. Милләтебезнең матур җырларында тальян моңнарында аның теле, гореф-гадәтләре, мәдәнияте яшәгәнлеген әйтергә тели автор.

Гомумән, җыр сәнгате гасырлардан гасырларга халкыбызның гореф-гадәтләрен, тел байлыгын, дөньяга карашын, тормыш итү, фикерләү үзенчәлекләрен чагылдыруда, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебезне саклау һәм яшәтүдә, милләтебезнең йөзен башка халыклар арасында үз урынын билгеләүдә мөһим роль уйный.

Шагыйрь иҗатында бер бик матур тема – ул анага мәхәббәт. Безнен әдәбиятта бу – тирән эшкәртелгән тема. Тукайнын җаннарны тетрәндерерлек шигъри юлларын гына алыйк.

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?
Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрен ташы
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы.

Әнвәр Шәрипов ана темасын «Әнкәй хатлары» (Р.Зарипов көе) дигән җырында бөтенләй үзенчә һәм лирик нечкәлек белән яңгырата.

«Лирик поэзиянең үзенчәлекле төре – җыр жанры – һәрвакыттагычা шигъриятнең игътибар үзәгендә булды» – дип яза әдәбият галиме Т. Галиуллин.

Аның лирик «әнкәсе» – үзе бер зур дөнья. Әнисенә булган тирән мәхәббәтен соклану, горурлану хисләре аша белдерә шагыйрь.

Җан җылысы белән еретелгән
Газиз әнкәемнең хатлары.
Мин аларны әнкәй төсе итеп,
Изге ядкарь итеп саклармын.

Музыкаль әсәрнең тууында шигъри сүз дә, музыка да бер ук дәрәҗәдә җитди роль уйный. Һәм синкретик характерда булуын билгеләп үтәргә кирәк. Ягъни, җырның сүзләре белән көе бергә укмашканда гына һәм башкару осталыгы берләшкәндә генә әсәр бербөтен була ала. Үзешчән композитор, автор башкаручы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рубис абый Зарипов белән Ә. Шәрипов һаман да иҗади дуслыкта. Аларның бергәләп иҗат

иткән җырлары радио һәм телевидениедән еш яңгырый һәм халкыбызның яраткан җырларына әверелде.

Тормышны җыр һәм музыкадан башка да күз алдына китерә алмый шагыйрь.

Йомгаклап әйткәндә, Әнвәр Шәриповның җырларында дөнья авазы да, табигать һәм җәмгыятьтәге вакыйгаларга, күренешләргә үз күзе белән карап, үз йөрәге белән тойган тирән чынбарлык та, ялкынлы мәхәббәт тә бар.